ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

1. 2019 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 237 023 276,8 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 241 174 553,7 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 4 151 276,9 мең сум итеп.

2. 2020 елга һәм 2021 елга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикаларын түбәндәгечә расларга:

1) Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләмен 2020 елга 235 191 063,8 мең сум һәм 2021 елга 240 735 927,1 мең сум итеп;

2) Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 2020 елга 239 949 857,9 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 6 420 000,0 мең сум итеп һәм 2021 елга 246 086 225,6 мең сум, шул исәптән шартлыча расланган чыгымнарны 12 320 000,0 мең сум итеп;

3) Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын 2020 елга 4 758 794,1 мең сум, 2021 елга 5 350 298,5 мең сум итеп.

3. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

1. 2020 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 94 205 117,6 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 9 907 800,0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2021 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 93 632 003,3 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 9 907 800,0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2022 елның 1 гыйнварына Татарстан Республикасы дәүләт эчке бурычының иң югары чиген 92 485 774,7 мең сум, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт гарантияләре буенча бурычның иң югары чиген 9 907 800,0 мең сум күләмендә расларга.

4. Татарстан Республикасы дәүләт бурычының иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2019 елга – 111 815 696,6 мең сум күләмендә;

2) 2020 елга – 111 753 643,3 мең сум күләмендә;

3) 2021 елга – 111 741 605,0 мең сум күләмендә.

5. 2019 елга Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасын, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасын әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә расларга.

6. 2019 елда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларны тулыландыру өчен Татарстан Республикасы бюджетына федераль бюджеттан бюджет кредитлары җәлеп итү юлы белән Татарстан Республикасы исеменнән Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашуларын башкару хокукы бирергә.

**3 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәрен әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $60^1$ статьясындагы 2 пункты нигезендә 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр бүлү нормативларын әлеге Законга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

**5 статья**

2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган автомобиль бензинына һәм турыдан-туры куыла торган бензинга, дизель ягулыгына, дизельле һәм (яисә) карбюраторлы (инжекторлы) двигательләр өчен мотор майларына акцизлардан җирле бюджетларга күчерелә торган түләүләрнең Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 41 статьясы нигезендә җирле бюджетларга күчерелергә тиешле дифференциацияләнгән нормативлары күләмнәрен әлеге Законга 5 нче кушымта нигезендә расларга.

**6 статья**

1. Акцияләре Татарстан Республикасы милкендә булган акционер җәмгыятьләрнең идарә органнарындагы дәүләт вәкилләре, 2018 ел нәтиҗәләре буенча чиста табыштан файдалану һәм дивидендлар түләү мәсьәләләре буенча акционер җәмгыятьләрнең идарә органнары (директорлар советы, күзәтчелек советы, акционерларның гомуми җыелышы) тарафыннан карарлар кабул ителгәндә, акцияләр буенча дивидендларны 2019 елның 1 сентябренә кадәр (әгәр җәмгыять уставында башка срок билгеләнмәгән булса) ел йомгаклары буенча чиста табышның кимендә 30 проценты күләмендә акчалата түләү өчен тавыш бирергә тиеш.

2. 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиеләре табышының 2018 ел йомгаклары буенча салымнарны түләгәннән һәм башка мәҗбүри түләүләрне башкарганнан соң калган өлеше 2019 елның 1 июленә кадәр әлеге табышның 30 проценты күләмендә кертелә дип билгеләргә.

**7 статья**

1. Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 6 нчы кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының баш администраторлары исемлеген әлеге Законга 7 нче кушымта нигезендә расларга.

**8 статья**

1. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге Законга 8 нче кушымта нигезендә расларга.

2. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге Законга 9 нчы кушымта нигезендә расларга.

3. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең максатчан статьялары (Татарстан Республикасы дәүләт программалары һәм эшчәнлекнең программага карамаган юнәлешләре), чыгымнар төрләре төркемнәре, бүлекләре, бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге Законга 10 нчы кушымта нигезендә расларга.

4. Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләренең гавами норматив йөкләмәләрне үтәүгә юнәлдерелә торган гомуми күләмен 2019 елга 19 272 264,4 мең сум, 2020 елга 19 903 981,0 мең сум һәм 2021 елга 20 550 714,1 мең сум күләмендә расларга.

5. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 77 статьясындагы 3 пунктына таянып, Татарстан Республикасы бюджетының җыелма бюджет язмасы күрсәткечләренә 2019 елда үзгәрешләр кертү әлеге статьяда расланган, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына каралган бюджет ассигнованиеләре составында резервланган бюджетлар чыгымнары классификациясендә «Гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлегенең «Башка гомумдәүләт мәсьәләләре» бүлекчәсе буенча оешмалар мөлкәтенә салым һәм җир салымын түләүгә 1 651 982,2 мең сумга кадәр күләмдә бүлүгә нигезләнә дип билгеләргә.

**9 статья**

Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, физик затларга – товарлар (эшләр, хезмәт күрсәтүләр) җитештерүчеләргә субсидияләр, үз керемнәре һәм Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары исәбеннән финанслана торган субвенцияләр, бюджетара субсидияләр, әлеге Законда каралган башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә бирелә.

**10 статья**

1. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә 2019 елда, 2020 һәм 2021 еллар план чорында җирле бюджетлардан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен әлеге Законга 11 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{10}$ статьясы нигезендә җирле бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле субсидия күләме, бер кешегә исәпләгәндә, аерым муниципаль берәмлек өчен хисап финанс елында җирле бюджетның бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәре (түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәрен исәпкә алмыйча) һәм бер кешегә исәпләп чыгарылган салым керемнәренең 1,3 тапкыр арттырылган уртача дәрәҗәсе арасындагы аерманың 2019 елда 3 процентын, 2020 елда 7 процентын, 2021 елда 7 процентын тәшкил итә дип билгеләргә.

**11 статья**

1. 2019 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр бирүгә кагылышлы өлешендә 43 857,8 мең сум итеп расларга һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә 43 857,8 мең сум күләмендә бирергә.

2. 2020 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр бирүгә кагылышлы өлешендә 35 916,6 мең сум итеп расларга һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә 35 916,6 мең сум күләмендә бирергә.

3. 2021 елга җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен шәһәр округларына дотацияләр бирүгә кагылышлы өлешендә 26 757,9 мең

сум итеп pacларга һәм күрсәтелгән дотацияләрне «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенә 26 757,9 мең сум күләмендә бирергә.

4. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына дотацияләр исәпләү һәм бирү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр исәпләп чыгарганда һәм муниципаль районнар бюджетларына субвенцияләр исәпләп чыгарганда кулланыла торган шәһәр җирлекләренең (шәһәр округларын кертеп), авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен күрсәтелгән муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашыру буенча финанс мөмкинлекләрен тигезләү критерийлары күрсәткечен түбәндәгечә билгеләргә:

1) шәһәр җирлекләре буенча (шәһәр округларын кертеп): бер кешегә исәпләгәндә 2019 елга – 1 305,5 сум, 2020 елга – 1 304,1 сум, 2021 елга – 1 296,6 сум итеп;

2) авыл җирлекләре буенча: бер кешегә исәпләгәндә 2019 елга – 245,9 сум, 2020 елга – 245,8 сум, 2021 елга – 228,7 сум итеп.

**12 статья**

1. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен түбәндәгечә расларга:

1) 2019 елга – 12 353 853,0 мең сум күләмендә;

2) 2020 елга – 12 965 362,5 мең сум күләмендә;

3) 2021 елга – 13 604 221,1 мең сум күләмендә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән дотацияләрне 2019 елда 11 645 479,8 мең сум, 2020 елда 12 327 094,4 мең сум, 2021 елда 13 095 442,1 мең сум күләмендә физик затлар керемнәренә салымнан түләүләрнең өстәмә нормативлары белән алмаштырырга.

3. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр бүлүне һәм физик затлар керемнәренә салымнан суммаларның шул дотацияләрне алмаштыра торган өстәмә нормативларын әлеге Законга 12 нче кушымта нигезендә расларга.

4. Муниципаль районнарның (шәһәр округларының) бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә дотацияләр күләмен билгеләгәндә кулланыла торган муниципаль районнарның (шәһәр округларының) хисаплы бюджет тәэмин ителешен тигезләү критерие күрсәткечләрен 2019 елга – 2,230, 2020 елга – 2,264, 2021 елга – 2,264 итеп билгеләргә.

**13 статья**

1. 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына бюджетара трансфертлар бүлүне әлеге Законга 13 – 35 нче кушымталар нигезендә расларга.

2. Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субсидияләр һәм башка бюджетара трансфертлар бүлү (бүлү әлеге Закон нигезендә расланган субсидияләрдән һәм башка бюджетара трансфертлардан тыш) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

**14 статья**

1. Татарстан Республикасы бюджетыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына эшләмәүче халыкны мәҗбүри медицина иминләштерүенә иминият кертемнәрен түләүгә җибәрелә торган бюджет ассигнованиеләре күләмен 2019 елга 14 314 496,9 мең сум, 2020 елга 14 864 631,9 мең сум, 2021 елга 15 453 016,0 мең сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар күләмен 2019 елга 8 551 238,3 мең сум, 2020 елга 8 659 617,1 мең сум, 2021 елга 8 775 870,7 мең сум күләмендә расларга.

3. Әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар 2019 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына ай саен күчерелә дип билгеләргә.

**15 статья**

Татарстан Республикасы Юллар фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2019 елга 25 018 769,5 мең сум, 2020 елга 24 137 528,1 мең сум, 2021 елга 24 147 398,3 мең сум күләмендә расларга һәм аларны 2019, 2020 һәм 2021 елларга Татарстан Республикасының гомуми файдалану юлларында юл эшләре программасы гамәлләрен тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**16 статья**

Инвестиция салым кредитларын бирүгә юнәлдерелә торган акчаларның иң чик күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1) 2019 елга –100 000,0 мең сум;

2) 2020 елга –100 000,0 мең сум;

3) 2021 елга –100 000,0 мең сум.

**17 статья**

1. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары 2019 елда Татарстан Республикасы дәүләт хезмәткәрләренең, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениеләрендә эшләүчеләрнең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуксыз.

2. Җирле үзидарә органнарына 2019 елда муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук җирле үзидарә органнары һәм муниципаль казна учреждениеләрендә эшләүчеләрнең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәүне тәкъдим итәргә.

**18 статья**

1. 2019 елда Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын баш бүлүчеләрнең карарлары нигезендә Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга максатчан билгеләнешкә ия субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә җирле бюджетлар акчаларын алучыларның чыгымнары буенча акчалата йөкләмәләрне түләү өчен әлеге бюджетара трансфертлар финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган кирәкле сумма чикләрендә бюджетара трансфертлар күчерү буенча Федераль казначылык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы вәкаләте тапшырыла дип билгеләргә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә каралган бюджетара трансфертлар исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

**19 статья**

Татарстан Республикасы бюджетында түбәндәгеләрдән алына торган бюджетара трансфертларны һәм кире кайтарылмый торган акчаларны әлеге Законга 36 нчы кушымта нигезендә исәпкә алырга:

1) федераль бюджеттан 2019 елда 28 891 236,4 мең сум, 2020 елда 24 426 865,5 мең сум һәм 2021 елда 23 130 780,4 мең сум күләмендә;

2) «Моношәһәрләрне үстерү фонды» коммерциягә карамаган оешмасыннан 2019 елда 169 473,7 мең сум күләмендә.

**20 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары Татарстан Республикасы бюджетын үтәүне, шулай ук төзелгән килешүләр нигезендә муниципаль берәмлекләр бюджетларын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыра.

**21 статья**

Товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары буенча түләү өчен бирелеп, әлеге дәүләт контрактлары шартлары нигезендә 2018 елда түләнергә тиешле файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләренең, җирле бюджет акчаларын алучыларның финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән бюджетара трансфертлар булган акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны бирүгә 2018 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелгән максатчан юнәлештәге бюджет ассигнованиеләренең, 2018 елда финанс белән тәэмин итү чыганагы күрсәтелгән субсидияләр булган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә бирелгән субсидияләрне юридик затларга бирүгә бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмаган күләмдә 2019 елда, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан тиешле карар кабул ителгән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәрелә.

**22 статья**

Суд эшчәнлеге турындагы, башкару эшчәнлеге турындагы һәм бөлгенлек (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә һәм очракларда Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексының $93^2$ статьясындагы 11 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына таянып, Татарстан Республикасы алдында акчалата йөкләмәләре буенча бурычлыларның бурычын җайга салу шартларын билгели торган, йөкләмәләр үтәүне кичектереп тору, йөкләмәләрне өлешләп үтәү турында, шулай ук бурычлыларны исәпләнгән пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләүдән тулысынча яисә өлешчә азат итү юлы белән йөкләмәләр күләмен киметү турында уртак килешүләр төзергә хокуклы.

**23 статья**

2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорга түбәндәгеләрнең гамәлдә булуын туктатып торырга:

1) «Яшь гаиләләргә торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законының 10 статьясындагы беренче өлешенең (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш) Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән дәүләт ярдәмен финанслау өлешендә;

2) «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясындагы 12 өлешенең беренче абзацының (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1, № 9 (II өлеш); 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш);

3) «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының

9 статьясындагы 4 өлешенең беренче абзацы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 4 (I өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2016, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 38 (I өлеш);

4) «Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары җирле үзидарә органнарына күпфатирлы йортларны һәм (яисә) күчемсез мөлкәтнең бүтән объектларын өлешле төзү өлкәсендә, шулай ук торак-төзелеш кооперативларының күпфатирлы йортларны төзүгә бәйле эшчәнлеген дәүләт тарафыннан тикшереп торуны (күзәтчелек итүне) гамәлгә ашыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2007 елның 27 декабрендәге 66-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацының (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 12 (II өлеш); 2010, № 5 (I өлеш), № 7 (II өлеш), № 12 (II өлеш); 2011, № 8 (I өлеш); 2013, № 3, № 10; 2014, № 7; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш), Казан шәһәре, «Чаллы шәһәре», Әгерҗе муниципаль районы, Әлмәт муниципаль районы, Баулы муниципаль районы, Югары Ослан муниципаль районы, Биектау муниципаль районы, Алабуга муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы, Лаеш муниципаль районы, Түбән Кама муниципаль районы, Питрәч муниципаль районы муниципаль берәмлекләре җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш;

5) «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарның аерым категорияләре өчен җәмәгать транспорты хезмәтләреннән бертигез дәрәҗәдә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү өлкәсендә аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2008 елның 19 декабрендәге 123-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы икенче абзацы (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 10), Казан шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнарына дәүләт вәкаләтләрен бирүдән тыш.

**24 статья**

Әлеге Закон 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                                                    Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 21 ноябрь
№ 88-ТРЗ

«2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

1 нче таблица

## 2019 елга
## Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 4 151 276,9 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары | -286 557,2 |
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | -286 557,2 |
| 01 03 01 00 00 0000 700 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары алу | 20 000 000,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар алу | 20 000 000,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын каплау | -20 286 557,2 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау, | -20 286 557,2 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | шул исәптән: федераль бюджеттан бүлеп бирелгән һәм «2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары нигезендә реструктуризация үткән бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны кайтаруга юнәлдерелә торган акчалар | -286 557,2 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 4 425 904,1 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган чараларын арттыру | -266 943 006,8 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка чараларын арттыру | -266 943 006,8 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | -266 943 006,8 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын арттыру | -266 943 006,8 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган чараларын киметү | 271 368 910,9 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка чараларын киметү | 271 368 910,9 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 271 368 910,9 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын киметү | 271 368 910,9 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | 11 930,0 |
| 01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -9 907 800,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -9 907 800,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -9 907 800,0 |
| 01 06 04 02 02 0000 820 | Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -9 907 800,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 000 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 11 930,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 600 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 11 930,0 |
| 01 06 05 02 00 0000 600 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 11 930,0 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы |
| --- | --- | --- |
| 01 06 05 02 02 0000 640 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларына Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 11 930,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалары) | 9 907 800,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 9 907 800,0 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 9 907 800,0 |
| Барлык чыганаклар | | 4 151 276,9 |

2 нче таблица

## 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары

(мең сумнарда)

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел |
| 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | 4 758 794,1 | 5 350 298,5 |
| 01 03 00 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан бюджет кредитлары | -573 114,3 | -1 146 228,6 |
| 01 03 01 00 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | -573 114,3 | -1 146 228,6 |
| 01 03 01 00 00 0000 700 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында бюджет кредитлары алу | 20 000 000,0 | 20 000 000,0 |
| 01 03 01 00 02 0000 710 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кредитлар алу | 20 000 000,0 | 20 000 000,0 |
| 01 03 01 00 00 0000 800 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган бюджет кредитларын каплау | -20 573 114,3 | -21 146 228,6 |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан Россия Федерациясе валютасында алынган кредитларны Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан каплау, | -20 573 114,3 | -21 146 228,6 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел |
| 01 03 01 00 02 0000 810 | шул исәптән: федераль бюджеттан бүлеп бирелгән һәм «2017 елда Россия Федерациясе алдында Россия Федерациясе субъектларының бюджет кредитлары буенча йөкләмәләренә (бурычларына) реструктуризация үткәрү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 13 декабрендәге 1531 номерлы карары нигезендә реструктуризация үткән бюджет кредитлары буенча реструктуризацияләнгән бурычны кайтаруга юнәлдерелә торган акчалар | -573 114,3 | -1 146 228,6 |
| 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар чараларын исәпкә алу счетларында калган чараларны үзгәртү | 5 331 908,4 | 6 126 527,1 |
| 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган чараларын арттыру | -265 098 863,8 | -271 013 727,1 |
| 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка чараларын арттыру | -265 098 863,8 | -271 013 727,1 |
| 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | -265 098 863,8 | -271 013 727,1 |
| 01 05 02 01 02 0000 510 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын арттыру | -265 098 863,8 | -271 013 727,1 |
| 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган чараларын киметү | 270 430 772,2 | 277 140 254,2 |
| 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка чараларын киметү | 270 430 772,2 | 277 140 254,2 |
| 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 270 430 772,2 | 277 140 254,2 |
| 01 05 02 01 02 0000 610 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларының калган башка акчаларын киметү | 270 430 772,2 | 277 140 254,2 |
| 01 06 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслауның башка чыганаклары | 0,0 | 370 000,0 |
| 01 06 04 00 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне үтәү | -9 907 800,0 | -9 907 800,0 |
| 01 06 04 02 00 0000 000 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -9 907 800,0 | -9 907 800,0 |

| Күрсәткеч коды | Күрсәткеч исеме | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел |
| 01 06 04 02 00 0000 800 | Дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән дәүләт һәм муниципаль гарантияләрне чит ил валютасында үтәү | -9 907 800,0 | -9 907 800,0 |
| 01 06 04 02 02 0000 820 | Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен гарант тарафыннан үтәү принципалга карата гарантның регресс таләбе хокукын барлыкка китергән очракта, максатчан чит ил кредитларыннан (хисаплашулардан) файдалану кысаларында Россия Федерациясенә бирелгән Россия Федерациясе субъекты дәүләт гарантияләрен чит ил валютасында үтәү | -9 907 800,0 | -9 907 800,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 000 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитлары | 0,0 | 370 000,0 |
| 01 06 05 00 00 0000 600 | Ил эчендә Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 0,0 | 370 000,0 |
| 01 06 05 01 00 0000 600 | Юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 0,0 | 370 000,0 |
| 01 06 05 01 02 0000 640 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан юридик затларга Россия Федерациясе валютасында бирелгән бюджет кредитларын кире кайтару | 0,0 | 370 000,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 000 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитлары (ссудалары) | 9 907 800,0 | 9 907 800,0 |
| 01 06 08 00 00 0000 600 | Ил эчендә бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 9 907 800,0 | 9 907 800,0 |
| 01 06 08 00 02 0000 640 | Ил эчендә Россия Федерациясе субъектлары бюджетыннан бирелгән башка бюджет кредитларын (ссудаларын) кире кайтару | 9 907 800,0 | 9 907 800,0 |
| Барлык чыганаклар | | 4 758 794,1 | 5 350 298,5 |

«2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

1 нче таблица

# 2019 елга Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасы

(мең сумнарда)

| | Суммасы |
|---|---|
| Эчке дәүләт хисаплашулары | |
| жәлеп итү | 20 000 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 20 286 557,2 |
| шул исәптән: | |
| бюджет кредитлары | |
| җәлеп итү | 20 000 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 20 286 557,2 |
| шул исәптән: | |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларга өстәү өчен федераль бюджеттан бюджет кредитлары | |
| җәлеп итү | 20 000 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 20 000 000,0 |

2 нче таблица

2020 һәм 2021 еллар план чорына
Татарстан Республикасы эчке дәүләт хисаплашулары программасы

(мең сумнарда)

| | Суммасы | |
|---|---|---|
| | 2020 ел | 2021 ел |
| Эчке дәүләт хисаплашулары | | |
| җәлеп итү | 20 000 000,0 | 20 000 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 20 573 114,3 | 21 146 228,6 |
| шул исәптән: | | |
| бюджет кредитлары | | |
| җәлеп итү | 20 000 000,0 | 20 000 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 20 573 114,3 | 21 146 228,6 |
| шул исәптән: | | |
| Россия Федерациясе субъектлары бюджетлары счетларында калган акчаларга өстәү өчен федераль бюджеттан бюджет кредитлары | | |
| җәлеп итү | 20 000 000,0 | 20 000 000,0 |
| бурычның төп суммасын каплауга җибәрелә торган акчалар күләме | 20 000 000,0 | 20 000 000,0 |

«2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

1нче таблица

# 2019 елга
# Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре

(мең сумнарда)

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 1 00 00000 00 0000 000 | 207 888 262,8 |
| Табышка, керемнәргә салымнар | 1 01 00000 00 0000 000 | 144 111 572,4 |
| Оешмалар табышына салым | 1 01 01000 00 0000 110 | 89 691 000,0 |
| Физик затлар керемнәренә салым | 1 01 02000 01 0000 110 | 54 420 572,4 |
| Россия Федерациясе территориясендә реализацияләнә торган товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) салымнар | 1 03 00000 00 0000 000 | 28 947 900,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган акцизлы товарларга (продукциягә) акцизлар | 1 03 02000 01 0000 110 | 28 947 900,0 |
| Җыелма керемгә салымнар | 1 05 00000 00 0000 000 | 6 453 165,0 |
| Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 1 05 01000 00 0000 110 | 6 453 165,0 |
| Мөлкәткә салымнар | 1 06 00000 00 0000 000 | 21 882 036,9 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым | 1 06 02000 02 0000 110 | 17 101 317,6 |
| Транспорт салымы | 1 06 04000 02 0000 110 | 4 765 500,0 |
| Уен бизнесына салым | 1 06 05000 02 0000 110 | 15 219,3 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен салымнар, җыемнар һәм даими түләүләр | 1 07 00000 00 0000 000 | 8 661,0 |
| Файдалы казылмалар чыгаруга салым | 1 07 01000 01 0000 110 | 7 110,0 |
| Хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган һәм су биологик ресурслары объектларыннан файдаланган өчен җыемнар | 1 07 04000 01 0000 110 | 1 551,0 |
| Дәүләт пошлинасы | 1 08 00000 00 0000 000 | 866 911,0 |
| Россия Федерациясе гражданлыгы алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга, шулай ук Россия Федерациясенә керүгә яисә Россия Федерациясеннән чыгуга бәйле гамәлләр | 1 08 06000 01 0000 110 | 8 730,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| кылган өчен дәүләт пошлинасы | | |
| Дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук бүтән юридик әһәмиятле гамәлләр башкарган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 07000 01 0000 110 | 858 181,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 1 11 00000 00 0000 000 | 883 636,0 |
| Хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларындагы өлешләренә туры килә торган табыш яисә Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары яисә муниципаль берәмлекләр карамагындагы акцияләр буенча дивидендлар рәвешендәге керемнәр | 1 11 01000 00 0000 120 | 134 365,0 |
| Бюджетлар акчаларын урнаштырудан керемнәр | 1 11 02000 00 0000 120 | 500 000,0 |
| Ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар | 1 11 03000 00 0000 120 | 25 354,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) түләүле файдалануга тапшырган өчен аренда түләве йә башка түләү рәвешендә алына торган керемнәр | 1 11 05000 00 0000 120 | 130 674,0 |
| Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турындагы килешүләр буенча түләү | 1 11 05300 00 0000 120 | 2 216,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән түләүләр | 1 11 07000 00 0000 120 | 28 295,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган акчалар | 1 11 08000 00 0000 120 | 62 732,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 00000 00 0000 000 | 149 072,0 |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 1 12 01000 01 0000 120 | 100 506,0 |
| Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 02000 00 0000 120 | 28 300,0 |
| Урманнардан файдаланган өчен түләү | 1 12 04000 00 0000 120 | 20 266,0 |
| Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләр башкарудан) һәм дәүләт чыгымнарын | 1 13 00000 00 0000 000 | 1 563 667,5 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| компенсацияләүдән керемнәр | | |
| Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләр башкарудан) керемнәр | 1 13 01000 00 0000 130 | 563 667,5 |
| Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 02000 00 0000 130 | 1 000 000,0 |
| Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | 1 14 00000 00 0000 000 | 227 007,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләрнең күчемле мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр | 1 14 02000 00 0000 000 | 25 007,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен сатудан керемнәр | 1 14 06000 00 0000 430 | 202 000,0 |
| Административ түләүләр һәм җыемнар | 1 15 00000 00 0000 000 | 1 354,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль органнар (оешмалар) тарафыннан аерым функцияләр башкарган өчен алына торган түләүләр | 1 15 02000 00 0000 140 | 1 200,0 |
| Дәүләт экологик экспертизасы үткәрелергә тиешле документация заказчылары тарафыннан кертелә торган дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә чыгымнар сметасы нигезендә исәпләнгән җыемнар | 1 15 07000 01 0000 140 | 154,0 |
| Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | 1 16 00000 00 0000 000 | 2 748 030,0 |
| Товар базарларында конкуренция, финанс хезмәтләре күрсәтү базарында конкуренцияне яклау өлкәсендә монополиягә каршы законнарны, табигый монополияләр турындагы законнарны һәм бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 02000 00 0000 140 | 1 450,0 |
| Реклама турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 26000 01 0000 140 | 1 520,0 |
| Янгын куркынычсызлыгы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 27000 01 0000 140 | 1 500,0 |
| Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозулар өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 30000 01 0000 140 | 2 735 000,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнарын | 1 16 33000 00 000 140 | 2 510,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы |
|---|---|---|
| бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | | |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан бүтән кертемнәр | 1 16 90000 00 0000 140 | 6 050,0 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 00000 00 0000 000 | 45 250,0 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 05000 00 0000 180 | 45 250,0 |
| Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 00 00000 00 0000 000 | 29 135 014,0 |
| Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 02 00000 00 0000 000 | 28 965 540,3 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына субсидияләр (бюджетара субсидияләр) | 2 02 20000 00 0000 150 | 10 186 083,4 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына субвенцияләр | 2 02 30000 00 0000 150 | 7 150 481,6 |
| Башка бюджетара трансфертлар | 2 02 40000 00 0000 150 | 11 628 975,3 |
| Дәүләтнеке булмаган оешмалардан керүче кире кайтарылмый торган керемнәр | 2 04 00000 00 0000 000 | 169 473,7 |
| Барлык керемнәр | | 237 023 276,8 |

2 нче таблица

## 2020 һәм 2021 елларга Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең фаразлана торган күләмнәре

(мең сумнарда)

| Исеме | Керем коды | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел |
| Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 1 00 00000 00 0000 000 | 210 582 308,1 | 217 315 220,4 |
| Табышка, керемнәргә салымнар | 1 01 00000 00 0000 000 | 148 429 915,3 | 154 470 573,6 |
| Оешмалар табышына салым | 1 01 01000 00 0000 110 | 90 823 000,0 | 93 272 000,0 |
| Физик затлар керемнәренә салым | 1 01 02000 01 0000 110 | 57 606 915,3 | 61 198 573,6 |
| Россия Федерациясе территориясендә реализацияләнә торган товарларга (эшләргә, хезмәт күрсәтүләргә) салымнар | 1 03 00000 00 0000 000 | 28 177 100,0 | 27 237 600,0 |
| Россия Федерациясе территориясендә җитештерелә торган акцизлы товарларга (продукциягә) акцизлар | 1 03 02000 01 0000 110 | 28 177 100,0 | 27 237 600,0 |
| Җыелма керемгә салымнар | 1 05 00000 00 0000 000 | 6 698 384,0 | 8 165 138,0 |
| Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллануга бәйле рәвештә алына торган салым | 1 05 01000 00 0000 110 | 6 698 384,0 | 8 165 138,0 |
| Мөлкәткә салымнар | 1 06 00000 00 0000 000 | 20 794 932,2 | 21 003 733,7 |
| Оешмалар мөлкәтенә салым | 1 06 02000 02 0000 110 | 16 014 212,2 | 16 223 013,7 |
| Транспорт салымы | 1 06 04000 02 0000 110 | 4 765 500,0 | 4 765 500,0 |
| Уен бизнесына салым | 1 06 05000 02 0000 110 | 15 220,0 | 15 220,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен салымнар, җыемнар һәм даими түләүләр | 1 07 00000 00 0000 000 | 8 661,0 | 8 661,0 |
| Файдалы казылмалар чыгаруга салым | 1 07 01000 01 0000 110 | 7 110,0 | 7 110,0 |
| Хайваннар дөньясы объектларыннан файдаланган һәм су биологик ресурслары объектларыннан файдаланган өчен җыемнар | 1 07 04000 01 0000 110 | 1 551,0 | 1 551,0 |
| Дәүләт пошлинасы | 1 08 00000 00 0000 000 | 877 411,0 | 877 423,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел |
| Россия Федерациясе гражданлыгы алуга яисә Россия Федерациясе гражданлыгыннан чыгуга, шулай ук Россия Федерациясенә керүгә яисә Россия Федерациясеннән чыгуга бәйле гамәлләр кылган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 06000 01 0000 110 | 8 730,0 | 8 730,0 |
| Дәүләт теркәвенә алган өчен, шулай ук бүтән юридик әһәмиятле гамәлләр башкарган өчен дәүләт пошлинасы | 1 08 07000 01 0000 110 | 868 681,0 | 868 693,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәттән файдаланудан керемнәр | 1 11 00000 00 0000 000 | 890 031,0 | 921 744,0 |
| Хуҗалык ширкәтләренең һәм җәмгыятьләренең устав (җыелма) капиталларындагы өлешләренә туры килә торган табыш яисә Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары яисә муниципаль берәмлекләр карамагындагы акцияләр буенча дивидендлар рәвешендәге керемнәр | 1 11 01000 00 0000 120 | 143 860,0 | 175 570,0 |
| Бюджетлар акчаларын урнаштырудан керемнәр | 1 11 02000 00 0000 120 | 500 000,0 | 500 000,0 |
| Ил эчендә бюджет кредитлары бирүдән алынган процентлар | 1 11 03000 00 0000 120 | 25 350,0 | 25 350,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) түләүле файдалануга тапшырган өчен аренда түләве йә башка түләү рәвешендә алына торган керемнәр | 1 11 05000 00 0000 120 | 126 314,0 | 126 230,0 |
| Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләренә карата сервитут билгеләү турындагы | 1 11 05300 00 0000 120 | 2 213,0 | 2 300,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел |
| килешүләр буенча түләү | | | |
| Дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләрдән түләүләр | 1 11 07000 00 0000 120 | 29 062,0 | 29 062,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләр мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) залогка, ышанычлы идарәгә тапшырудан алына торган акчалар | 1 11 08000 00 0000 120 | 63 232,0 | 63 232,0 |
| Табигать ресурсларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 00000 00 0000 000 | 162 165,0 | 162 165,0 |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясаган өчен түләү | 1 12 01000 01 0000 120 | 111 554,0 | 111 554,0 |
| Җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләр | 1 12 02000 00 0000 120 | 28 300,0 | 28 300,0 |
| Урманнардан файдаланган өчен түләү | 1 12 04000 00 0000 120 | 22 311,0 | 22 311,0 |
| Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләр башкарудан) һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 00000 00 0000 000 | 1 566 163,6 | 1 568 734,1 |
| Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән (эшләр башкарудан) керемнәр | 1 13 01000 00 0000 130 | 566 163,6 | 568 734,1 |
| Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 1 13 02000 00 0000 130 | 1 000 000,0 | 1 000 000,0 |
| Матди һәм матди булмаган активларны сатудан керемнәр | 1 14 00000 00 0000 000 | 183 007,0 | 105 007,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге мөлкәтне (бюджет һәм автоном учреждениеләрнең күчемле мөлкәтеннән, шулай ук дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, шул исәптән казна предприятиеләре мөлкәтеннән тыш) реализацияләүдән керемнәр | 1 14 02000 00 0000 000 | 25 007,0 | 25 007,0 |
| Дәүләт милкендәге һәм муниципаль милектәге җир кишәрлекләрен сатудан | 1 14 06000 00 0000 430 | 158 000,0 | 80 000,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел |
| керемнәр | | | |
| Административ түләүләр һәм җыемнар | 1 15 00000 00 0000 000 | 1 355,0 | 1 355,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль органнар (оешмалар) тарафыннан аерым функцияләр башкарган өчен алына торган түләүләр | 1 15 02000 00 0000 140 | 1 200,0 | 1 200,0 |
| Дәүләт экологик экспертизасы үткәрелергә тиешле документация заказчылары тарафыннан кертелә торган дәүләт экологик экспертизасы үткәрүгә чыгымнар сметасы нигезендә исәпләнгән җыемнар | 1 15 07000 01 0000 140 | 155,0 | 155,0 |
| Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | 1 16 00000 00 0000 000 | 2 747 933,0 | 2 747 836,0 |
| Товар базарларында конкуренция, финанс хезмәтләре күрсәтү базарында конкуренцияне яклау өлкәсендә монополиягә каршы законнарны, табигый монополияләр турындагы законнарны һәм бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 02000 00 0000 140 | 1 350,0 | 1 250,0 |
| Реклама турындагы законнарны бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 26000 01 0000 140 | 1 520,0 | 1 520,0 |
| Янгын куркынычсызлыгы турында Россия Федерациясе законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 27000 01 0000 140 | 1 500,0 | 1 500,0 |
| Юл хәрәкәте өлкәсендә хокук бозулар өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | 1 16 30000 01 0000 140 | 2 735 000,0 | 2 735 000,0 |
| Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе | 1 16 33000 00 000  140 | 2 510,0 | 2 510,0 |

| Исеме | Керем коды | Суммасы | |
|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел |
| законнарын бозган өчен акчалата түләтүләр (штрафлар) | | | |
| Зыянны каплауга акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) һәм башка суммалардан бүтән кертемнәр | 1 16 90000 00 0000 140 | 6 053,0 | 6 056,0 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 00000 00 0000 000 | 45 250,0 | 45 250,0 |
| Салым булмаган башка керемнәр | 1 17 05000 00 0000 180 | 45 250,0 | 45 250,0 |
| Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 00 00000 00 0000 000 | 24 608 755,7 | 23 420 706,7 |
| Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан керүче кире кайтарылмый торган кертемнәр | 2 02 00000 00 0000 000 | 24 608 755,7 | 23 420 706,7 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына субсидияләр (бюджетара субсидияләр) | 2 02 20000 00 0000 150 | 10 895 436,1 | 10 269 110,4 |
| Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына субвенцияләр | 2 02 30000 00 0000 150 | 7 215 574,9 | 7 271 119,8 |
| Башка бюджетара трансфертлар | 2 02 40000 00 0000 150 | 6 497 744,7 | 5 880 476,5 |
| Барлык керемнәр | | 235 191 063,8 | 240 735 927,1 |

«2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» Татарстан Республикасы Законына
4 нче кушымта

## 2019 елга, 2020 һәм 2021 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетлары арасында керемнәр бүлү нормативлары

(процентларда)

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| 1 05 00000 00 0000 000 | Җыелма керемгә салымнар | | | | | | |
| 1 05 01021 01 0000 110 | Салым салу объекты буларак чыгымнар күләменә киметелгән керемнәрне сайлаган салым түләүчеләрдән алына торган салым (шул исәптән Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган минималь салым) | 70 | 30 | 30 | | | |
| 1 05 01050 01 0000 110 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына күчерелә торган минималь салым (2016 елның 1 гыйнварына тәмамланган салым чорлары өчен) | 100 | | | | | |
| 1 05 03020 01 0000 110 | Бердәй авыл хуҗалыгы салымы (2011 елның 1 гыйнварына тәмамланган салым чорлары өчен) | | 90 | 60 | 30 | 30 | |
| 1 09 00000 00 0000 000 | Юкка чыгарылган салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурыч һәм яңадан исәпләүләр | | | | | | |
| 1 09 04010 02 0000 110 | Предприятиеләр мөлкәтенә салым | 100 | | | | | |
| 1 09 06010 02 0000 110 | Сатулардан салым | 100 | | | | | |
| 1 09 06020 02 0000 110 | Мәгариф учреждениеләре ихтыяҗларына юридик | 100 | | | | | |

| Код | Керемнәр төркемнәре, төркемчәләре, статьялары һәм ярдәмче статьялары исеме | Татарстан Республикасы бюджеты | Җирле бюджетлар | | | | Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | шәһәр округлары | муниципаль районнар | авыл җирлекләре | шәһәр җирлекләре | |
| | затлардан алына торган җыем | | | | | | |
| 1 09 06030 02 0000 110 | Башка салымнар һәм җыемнар | 100 | | | | | |
| 1 09 07012 04 0000 110 | Шәһәр округлары территорияләрендә туплана торган реклама салымы | | 100 | | | | |
| 1 09 07013 05 0000 110 | Муниципаль районнар территорияләрендә туплана торган реклама салымы | | | 100 | | | |
